КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 14 сентябрь г.Казань № 1000

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Устав капиталын арттыру өчен Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 11 сентябрь, 862 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Устав капиталын арттыру өчен Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 11 сентябрь, 862 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 30 март, 291 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар исемендә «капиталын» сүзен «фондын» сүзенә алмаштырырга;

1 пунктта «капиталын» сүзен «фондын» сүзенә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Устав капиталын арттыру өчен Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибендә:

исемендә «капиталын» сүзен «фондын» сүзенә алмаштырырга;

1.1 пунктта «капиталын» сүзен «фондын» сүзенә алмаштырырга;

1.2 пунктта «капиталын» сүзен «фондын» сүзенә алмаштырырга;

2.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмау.»;

3.2 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучының, субсидияләр алучылар белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалыгы;»;

3.4 пунктта «капиталын» сүзен «фондын» сүзенә алмаштырырга;

4.2 пунктта «һәм субсидиянең максатчан файдаланылмавы» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Министрлык субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары үтәлешен (шул исәптән бу Тәртиптә һәм Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) тикшерүне гамәлгә ашырырга.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.»;

5.5 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

Тәртипнең кушымтасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Тәртипнең 2.3 пунктындагы өченче абзацының, Тәртип кушымтасының 6 пункттагы өченче абзацының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Устав фондын арттыру өчен
Татарстан Республикасы дәүләт
унитар предприятиесенә Татарстан
Республикасы бюджетыннан
субсидия бирү тәртибенә
кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 14 сентябрь, 1000 нче
карары редакциясендә)

Форма

Устав фондын арттыру өчен
Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенә
Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү өчен
сайлап алуда катнашуга тәкъдим (заявка)

1. Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенең тулы исеме: ______
______________________________________________________________________

2. Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенең юридик адресы: __
______________________________________________________________________

телефоны: _________________ e-mail: ________________________________________

3. Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе җитәкчесенең (вәкаләтле затның) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), вазифасы: _________________________________________________________________
______________________________________________________________________

телефоны: _________________ e-mail: ________________________________________

4. Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эшчәнлек төрләре турында мәгълүмат: _________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

5. Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенең реквизитлары:
салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры: _______________________________
исәпкә куелу сәбәбенең коды: _____________________________________________
төп дәүләт теркәү номеры: _______________________________________________
исәп-хисап счеты: ______________________________________________________
банкның исеме һәм урнашу урыны: _________________________________________
______________________________________________________________________

корреспондентлык счеты: ___________________________________________

банк идентификация коды (БИК): ____________________________________

6. Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенең:

салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе юк;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлары, шулай ук Татарстан Республикасы каршында акча йөкләмәләре буенча вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлары юк;

үзгәртеп оештыру (предприятиегә башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында түгел, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәгән һәм аның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки юридки зат булган грант алырга теләүченең баш бухгалтеры турында мәгълүматлар бирелмәгән;

чит ил юридик заты, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган, салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләрен уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган, устав (җыелма) капиталында чит илләр юридик затларының катнашу өлеше барысы бергә җыеп исәпләгәндә 50 проценттан артмаган Россия юридик заты түгел;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 11 сентябрь, 862 нче карары белән расланган Устав фондын арттыру өчен Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы түгел;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бара дип раслыйм.

7. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (https://minstroy.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе турында, Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе тарафыннан бирелә торган заявка турында мәгълүмат, сайлап алу үткәрүгә бәйле Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе турында башка мәгълүмат бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалык бирәм.

Татарстан Республикасы
дәүләт унитар предприятиесе җитәкчесе (вәкаләтле зат)

________________/______________/_________________________
(вазифасы) (имзасы) (имзаны таркатып язу)

Башкаручы

________________/_______________/____________________________/_________________
(вазифасы) (имзасы) (имзаны таркатып язу) (телефоны)

20__ ел, «___» __________

_______________________________________